МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 189/о

ПРИКАЗ

БОЕРЫК

"26" 10 2017

Татарстан Республикасында кайнар су белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәт күрсәтү максатларында салкын су җылыту өчен кулланыла торган җылылык энергиясенең сарыф нормативларын раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Коммуналь хезмәтләрне куллану нормативларын һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту максатларында коммуналь хезмәтләрне куллану нормативларын билгеләү һәм ачыклау кагыйдәләрен раслау турында" 2006 елның 23 маендагы 306 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре" 2005 елның 06 июлендәге 313 номерлы карары нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасында кайнар су белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәт күрсәтү максатларында салкын су җылыту өчен кулланыла торган җылылык энергиясенең кушымтада бирелгән сарыф нормативларын расларга һәм 2017 елның 1 декабреннән гамәлгә кертергә.

2. Кайнар су белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәт күрсәтү максатларында салкын су җылыту өчен кулланыла торган җылылык энергиясенең сарыф нормативлары хисап методын кулланып билгеләнде.

3. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю. Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С. Миңнехановага әлеге боерыкны “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Бу боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрының беренче урынбасары А.М. Фроловка йөкләргә.

Министр И.Ә.Фәйзуллин

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм
торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының 2017 елның
"26" 10 №189/о
боерыгына кушымта

Татарстан Республикасында кайнар су белән тәэмин итү буенча
коммуналь хезмәт күрсәтү максатларында салкын су җылыту өчен кулланыла
торган җылылык энергиясенең сарыф нормативлары

Гкал/м3

| Кайнар су белән тәэмин итү системасы (ачык, ябык) | кайнар су белән тәэмин итүнең тышкы челтәре белән | кайнар су белән тәэмин итүнең тышкы челтәреннән башка |
|---|---|---|
| Изоляцияләнгән терәкләр белән: | | |
| сөлге киптергечләр белән | 0,0627 | 0,0602 |
| сөлге киптергечләрдән башка | 0,0577 | 0,0552 |
| Изоляцияләнмәгән терәкләр белән: | | |
| сөлге киптергечләр белән | 0,0678 | 0,0653 |
| сөлге киптергечләрдән башка | 0,0627 | 0,0602 |